# Алмаз Гыймадиев

1972



Алмаз Марс улы Гыймадиев 1972 елның 20 июлендә Татарстан Республикасының Биектау районы Олы Битаман авылында укытучылар гаиләсендә туа.



Әнисе, балалар язучысы Ләлә Нәгыйм кызы Сабирова (Гыймадиева) 1947 елның 1 мартында Татарстанның Дөбьяз районы Мәмдәл авылында (хәзер Биектау районына карый) укытучылар гаиләсендә туган.

1988 елда Олы Битаман урта мәктәбен тәмамлап, шул ук елны Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты һәм көнчыгыш телләре факультетына укырга керә. Университетның дүртенче курсында укыганда республика балалар һәм яшүсмерләр газетасы «Сабантуй» редакциясенә хәбәрче булып эшкә урнаша. Университетта укуын тәмамлагач та шул газетада 1996 елга кадәр эшләвен дәвам иттерә. 1996-1997 елларда Татарстанның Әтнә районы хакимиятендә мәдәният бүлеге мөдире булып эшли. 1997 елдан «Казан утлары» журналында: әүвәл редакциянең бүлек мөдире, 1998 елдан җаваплы секретарь вазифаларын башкара.

- А.Гыймадиев бала чагында ук хикәяләр, әкиятләр язу белән мавыга, мәктәптә укыганда аерым язмалары «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында, «Ялкын» журналында басыла башлый. Актив иҗат эшенә кереп китүе үткән гасырның туксанынчы елларына туры килә. 1997 елда аның балалар өчен кырыклап шаян хикәясен үз эченә алган «Тә-нә-фес, яки Маҗаралы хәлләр» исемле беренче китабы, 2000 елда «Хуш, Тамчыгөл!» дигән икенче җыентыгы дөнья күрә. Шушы ике җыентыгына тупланган әсәрләре өчен ул 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек була

- Алга таба, үзенең иҗат офыкларын киңәйтә барып, соңгы елларда А.Гыймадиев яшь укучыларына янә ике китабын – «Без андый малай түгел!» (2005) һәм «Ниязның рекордлар китабы» (2006) дип аталган хикәя-повесть җыентыкларын бүләк итә. Моннан тыш язучы иҗатыннан аерым хикәяләр «Хәтер» нәшриятында чыккан «Татар балалар әдәбияты» (2003) һәм Татарстан китап нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән «Бала-чакта калабыз» (2004) исемле күмәк җыентыкларда да лаеклы урын ала.

- А.Гыймадиевның хикәяләре композицион яктан җыйнак, сюжетлары мавҗаралы хәлләргә корылган булулары белән җәлеп итә, аларда балаларның көндәлек тормышта – мәктәптә, шәһәр урамында, авыл болын-кырларында бер-берсенә карата эчкерсез мөнәсәбәтләре, шаянлыклары, характер үзенчәлекләре кызыклы детальләр, тормышчан вакыйга-эпизодлар аша сурәтләнә.
- Ул 2007 елда Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби бүләгенә лаек була.
- А.Гыймадиев – 1998 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.


Без андый
малай түгел!


РЕКОРДЛАР
КИТАБЫ


Алмаз Гыймадиев
Телефонлы
кәҗә


ИКЕ ӘНИ
ҺӘМ БЕР
МАТЕМАТИКА


Ләлә Гыймадиева
МИН АҢА
БӘХЕТ ТЕЛИМ